**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

**I. Теоретик биремнәр (35 балл).**

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең авторын, төрен һәм жанрын билгеләгез (20 балл):

*“Гыйлемлек хак рәхмәтедер...” яки “Игенчегә Хак рәхмәте...”* **– *М.Колый, лирик төр яки поэзия, хикмәт***

*“Төхфәи мәрдан” –* ***Мөхәммәдъяр, поэзия яки лиро-эпик төр, поэма***

*“Хөсрәү вә Ширин” –* ***Котб, поэзия яки лиро-эпик төр, дастан***

*“Шәмдәлләрдә генә утлар яна” –* ***М.Юныс, проза яки эпик төр, повесть***

*“Кыйссаи Йосыф”* **– *Кол Гали, поэзия яки лиро-эпик төр, дастан***

2. Ф.Кәримнең “Сибәли дә сибәли” шигыреннән алынган әлеге өзекнең нинди үлчәмдә язылганлыгын билгеләгез (5 балл):

*Төнге җилдә көзге яңгыр*
*Сибәли дә сибәли;*
*Янымдагы иптәш кенә*
*Миңа берни сөйләми...* ***8 / 7.***

3. Әлеге билгеләмәләрдән әдәбият тарихы төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (5 балл):

*1)* ***әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;***

*2) әдәби тәнкыйтьне үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;*

*3) әдәби әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;*

*4) әдәби геройларны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән.*

4. Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында гашыйкларның мәхәббәт көчен тасвирлауда нинди әдәби алым еш кулланыла (5 балл):

*А) пейзаж*
*Б)* ***гипербола, чиктән тыш арттыру***
*В) психологик анализ*
*Г) портрет.*

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).**

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә Йосыф-Зөләйха яки Ширин-Фәрхад мәхәббәт тарихы ничек тәмамлана? (5 балл)

2. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә әдип ни өчен төп геройларын төрле авырлыклар алдына куеп сыный дип уйлыйсыз? ***Чиктән тыш сыйфатларга ия геройлар итеп сурәтләү максатыннан, аларга хас матур сыйфатларны көчәйтү өчен, сабырлыкларын күрсәтү өчен һ.б.*** (10 балл)

3. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә автор ни өчен мәхәббәтне илаһилаштыра дип уйлыйсыз? Үз фикерегезне дәлилләп бирегез ***Көнчыгыш әдәбиятына хас булганча, мәхәббәтне илаһилаштыру күзәтелә, чиктән тыш илаһилаштырылган, идеаллаштырылган геройларның мәхәббәте гади-гадәти генә итеп сурәтләнә алмый һ.б.*** (15 балл)

4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип саныйсыз? (үзегез сайлап алган әсәр мисалында аңлатыгыз) ***Мәңгелек мәхәббәт, күңел матурлыгы, диндә макталган яхшы сыйфатлар турында сөйли һ.б.*** (15 балл)

## III. Иҗади бирем (20 балл).

1. Мәхәббәт көче турында кечкенә генә хикәя языгыз.